**СОВЕТ УСАДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район, д.Тимофеевка, ул.Профсоюзная, 45

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УСАД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Тимофеевка авылы, Профсоюз . ур.,45

тел./факс 8(84365) 73-2-75, e-mail: Usad.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**14.08.2024 г.** **№ 112**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү турында «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлегендә бюджет процессы турында» 2021 елның 23 сентябрендәге 32 номерлы

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы прокуратурасының 23.07.02-08-01 номерлы протесты нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге советы **КАРАР ИТТЕ:**

1.«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлегендә бюджет процессы турында» 2021 елның 23 сентябрендәге 32 номерлы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге Советы карары (2021 елның 13 декабрендәге 37 номерлы, 2024 елның 13 февралендәге 95 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 статьяның 1 пунктында түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

«14. «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең интеграцияләнгән мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр, аларга федераль бюджет акчалары (капиталь төзелеш объектларыннан һәм дәүләт оборона заказына кертелгән күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) булган капитал салуларны финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы төзи.».

2. Әлеге карарны интернет челтәрендә аны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Усад Башлыгы
авыл җирлеге, Совет рәисе Р.Ф. Сибгатуллин